КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 апрель г.Казань № 487

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-житештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1475 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының» сүзләреннән соң «һәм «Этилен-600» индустриаль паркының» сүзләрен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2025 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларны (паркларын) төзү һәм үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының» сүзләреннән соң «һәм «Этилен-600» индустриаль паркының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

исемендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының» сүзләреннән соң «һәм «Этилен-600» индустриаль паркының» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктның беренче абзацында «сәнәгать технопарклары,» сүзләреннән соң – «югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар,» сүзләрен, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының» сүзләреннән соң «һәм «Этилен-600» индустриаль паркының» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Идарә итүче компания субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1есенә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча Килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1есеннән дә иртәрәк булмаган вакытта салым органы тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларны үтәү турында бирелгән белешмә кәгазен;»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

җыелма керем;

әлеге Тәртип нигезендә җыелма керемнең индустриаль парк проектын гамәлгә ашыру чорында бирелгән субсидиянең җыелма күләменә карата нисбәт коэффициенты;

индустриаль парк проектын гамәлгә ашыра башлаганнан алып эш урыннары саны;

индустриаль парк резидентлары саны (туплаган йомгак белән);

индустриаль парк территориясендә алына торган җыелма өстәлгән кыйммәт;

индустриаль парк проектын гамәлгә ашыруга кертелә торган бюджеттан тыш инвестицияләрнең фараз күләме;

индустриаль парк резидентлары биләгән индустриаль парк территориясе мәйданының индустриаль парк резидентларын урнаштыру өчен билгеләнгән индустриаль парк территориясенең гомуми мәйданына карата нисбәте;

индустриаль парк территориясенең 1 гектар гомуми мәйданына индустриаль парк резидентларының төп капиталына инвестицияләрнең чагыштырма күләме (тупланган йомгак белән);

индустриаль парк инфраструктурасын файдалануга тапшыру.

Әлеге пунктның икенче – җиденче һәм тугызынчы абзацларында каралган субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре һәм аларга ирешү сроклары Килешүдә индустриаль паркның комплекслы инвестиция проекты паспорты нигезендә билгеләнә.

Әлеге пунктның сигезенче абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече һәм аңа ирешү сроклары Килешүдә 1119 номерлы карар нигезендә билгеләнә.

Әлеге пунктның унынчы абзацында каралган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү сроклары Килешүдә билгеләнә.»;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта»;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидия бирүгә гариза»;

Тәртипнең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы

махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидия бирү өчен 2023 елга бюджет ассигнованиеләре карала торган «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы икенче, бишенче, җиденче, сигезенче, егерме җиденче – утыз икенче абзацлардан тыш, бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ»
дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча
төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының
бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү
тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль
паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының
идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү
тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык
җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 апрель, 487 нче
карары редакциясендә)

Форма

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркы буенча / «Этилен-600» индустриаль паркы буенча
исәп-хисап белешмә кәгазе

| Т/с | Объект исеме | Өстәлгән кыйммәткә салымсыз төзелешнең смета кыйммәте | ____ дан _____ кадәрге чорга башкарылган эшләр кыйммәте – өстәлгән кыйммәткә салымсыз барлыгы, сум | Кредит шартнамәсе буенча кредит суммасы, сум | Билгеләнгән чор ахырына карата кредит шартнамәсе буенча төп бурыч суммасы, сум | Заявка биргән датага кредит шартнамәсе буенча калган акча, сум | ____ дан _____ кадәрге чорга кредит шартнамәсе буенча төп бурычны каплау суммасы, сум | ____ дан _____ кадәрге чорга кредит шартнамәсе буенча процентларны каплау суммасы, сум | Сорала торган чорга элек бирелгән субсидиянең гомуми суммасы*, сум | Шул исәптән чыгымнарны каплауга | | | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 декабрь, 1003 нче; 2019 ел, 23 апрель, 332 нче* карарлары буенча элек бирелгән субсидиянең гомуми суммасы, сум | Шул исәптән | | Заявка биргән датага субсидиянең иң чик күләме, сум | Түләнергә тиешле чорга субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | 2022 ел | | 20__ ел | | | 2017 ел | 20__ ел | | |
| | | | | | | | | | | төп бурыч буенча | процентлар буенча | төп бурыч буенча | процентлар буенча | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 = 5 – 6 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 = ((3 – 15) + + 9) × | 19 = (8 + 9) × × 0,999, |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | × 0,999 − − 10 | әмма 18нче баганада-гы күр-сәткечтән артмаган санда |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инфраструктура объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының («Алабуга-2» индустриаль паркы) идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 декабрь, 1003 нче карары («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркына карата кулланыла).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 332 нче карары.

Субсидия күләме _____________ сум.

Идарә итүче компания җитәкчесе ________________________ ______________________________________

(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Баш бухгалтер ________________________ ______________________________________

(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

________________________________________